Сабыйга

5·6
2001

Признан победителем и награжден грантом "Фонда Сороса"

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ



Сабыйга

№ 5-6 (83-84) — 2001 ел
(май-июнь)

Мәктәпкәчә олы яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балаларының әдәби-нәфис журналы

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:
«Сабыйга» журналы редакциясе хезмәт коллективы, Казан шәһәре хакимияте, «Мирас» журналы редакциясе, Татарстан белем министрлыгы

Баш мөхәррир
МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Редакция советы:
Алла Айсина
Ирек Арсланов
Фаил Әхмәдиев
Мәхмүт Әхмәтҗанов
Әлфия Галимҗанова
Шәүкәт Галиев
Айрат Зарипов
Фирдәвес Зарифуллин
Лилия Сәхапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Зөфәр Хәкимов
Заһир Хәкимов
Әнәс Хәсәнов

Тышлыкта
Заһир Хәкимов рәсемнәре.

«Сабыйга» балалар журналының индексы — **73954.** Аңа Татарстан Республикасының,Русия Федерациясе составында булган республикаларның, край һәм өлкәләрнең, БДБ составына кергән дәүләтләрнең һәм чит илләрнең элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Журнал татар һәм урыс телләрендә нәшер ителә. Редакциянең адресы: 420066; Казан шәһәре,Чистай урамы,5 йорт. Бәйләнешкә керү өчен телефон: *(8432)* **49-35-54.** Журналга язылу һәм аны тарату мәсьәләләре буенча 38-59-78 номерлы телефон аша мөрәҗәгать итәргә, ә басманың сыйфатына кагылышлы дәгъваларны исә 43-27-73 номерлы телефон ярдәмендә белдерергә мөмкин. Иганәчеләр өчен журналның исәп-хисап саны **р/с № 40603810562260100025,** Россия Саклык банкының Татарстан Банкы 6672/0253. Корр. счеты **№ 30101810600000000603.** Журнал идеясенең һәм исеменең авторы М. Җ. Сәхапов. Гигиена сертификаты № 16.09.01. 952.П.0000 74.01.01.

«Сабыйга» журналы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 314 сан белән теркәлде. 1994 елның 1 июленнән бирле нәшер ителә.

Производствога бирелде 21.03.2001 ел. Басарга кул куелды 11.05.2001 ел. Форматы 84x108 1/16. Офсет кәгазе № 1. Күләме 5.50 басма табак. 5,55 нәшер-хисап табак. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 6000 данә. Заказ Э-524. Ваклап сатуда ирекле бәя.

«Идел-Пресс» дәүләт унитар предприятиесенең полиграфия-нәшрият комплексы. 420066; Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт.

© «Сабыйга», 2001 ел.

Ел фасыллары

МАЙ

МАЙ — КУАК ТӨБЕНДӘ ҖӘННӘТ.
МАЙ АЕНДА АТКА ПЕЧӘН САЛ,
Ә ҮЗЕҢ МИЧ БАШЫНА МЕНЕП ЯТ!
МАЙ ҮЛӘНЕ АЧНЫ ДА ТУЙДЫРА.

ИЮНЬ

МАЙ ИКМӘКНЕ БУЛДЫРА,
Ә ИЮНЬ — ПЕЧӘННЕ.
ИЮНЬ АЕНДА БЕРЕНЧЕ
ҖИЛӘКНЕ АВЫЗГА САЛАЛАР,
Ә ИКЕНЧЕСЕН ӨЙГӘ АЛЫП КИТӘЛӘР.
ҖӘЙНЕҢ БЕР КӨНЕ ЕЛНЫ ТУЙДЫРА.

Рәссам ИЛДАР ӘХМӘДИ

Художник ИЛДАР АХМАДИЕВ

Времена года

МАЙ

МАЙ — ПОД КУСТИКОМ РАЙ.
МАЙ — КОНЮ СЕНА ДАЙ,
А САМ НА ПЕЧЬ ПОЛЕЗАЙ!
МАЙСКАЯ ТРАВКА
И ГОЛОДНОГО КОРМИТ.

ИЮНЬ

МАЙ СОЗДАЕТ ХЛЕБА,
А ИЮНЬ — СЕНО.
В ИЮНЕ ПЕРВУЮ ЯГОДКУ В РОТ КЛАДУТ,
А ВТОРУЮ ДОМОЙ НЕСУТ.
ЛЕТНИЙ ДЕНЬ ГОД КОРМИТ.



Сабыйга

№ 5-6 (83-84) — 2001 г.
(май-июнь)

Литературно-художественный журнал для детей старшего дошкольного и младшего школьного возрастов

УЧРЕДИТЕЛИ:

Трудовой коллектив редакции журнала «Сабыйга», администрация г. Казани, редакция журнала «Мирас», Министерство образования Татарстана

Главный редактор
МИНАХМЕД САХАПОВ

Совет редакции:

Алла Айсина
Ирек Арсланов
Фаил Ахмадиев
Махмут Ахметзянов
Альфия Галимзянова
Шаукат Галиев
Айрат Зарипов
Фирдаус Зарифуллин
Лилия Сахапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Зуфар Хакимов
Загир Хакимов
Анас Хасанов

На обложке рисунки Загира Хакимова.

Индекс детского журнала «Сабыйга» — **73954.** Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях связи Республики Татарстан, в областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066; г. Казань, ул. Чистопольская, 5; а/я № 227. Тел.: *(8432)* **49-35-54.** По вопросам доставки и подписки обращаться по телефону 38-59-78, качества печати 43-27-73. Для спонсоров журнала: **р/с № 40603810562260100025** в Банке Татарстан Сбербанка России 6672/0253. **Корр. счет № 30101810600000000603** в РКЦ НБ РТ, БИК 049205603. ИНН № 1654002150. Код ОКОНХ — 87100, код ОКПО — 12986213. Автор идеи и названия журнала М. Ж. Сахапов. Гигиенический сертификат № 16.09.01.952. П.0000 74.01.01. от 24.01.2001 г.

Журнал «Сабыйга» зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 1 июля 1994 года.

Сдано в производство 21.03.2001 г. Подписано в печать 11.05.2001 г. Формат 84х108 /». Офсетная бумага № 1. Объем 5.50 п.л. Учетн.-изд. л. 5,55. Печатается офсетным способом. Тираж 6000 экз. Заказ Э-524. Цена договорная.

ГУП ПИК «Идел-Пресс». 420066; г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Сабыйга», 2001 г.

Шигъри бишек

ГӨЛЛӘРЕМ

ТӘРӘЗ ТӨБЕМДӘ ГӨЛЛӘР
ЕЛМАЕП УТЫРАЛАР.
МИНЕМ «БИШЛЕ» АЛГАННЫ
ӘЙТЕРСЕҢ, БЕЛӘ АЛАР.

ЙОМШАК, НӘФИС ЯФРАКЛАР,
ЧӘЧӘКЛӘРЕ АП-АКЛАР.
ЧУКЛАРЫ ЭНҖЕ КЕБЕК,
МИН АЛГАН «БИШЛЕ» КЕБЕК.

БЕРКӨННЕ МИН «ӨЧ» АЛДЫМ.
ГӨЛЛӘРЕМӘ КҮЗ САЛДЫМ:
ГӨЛЛӘРЕМ ШИҢГӘН ИДЕ,
БАШЛАРЫН ИГӘН ИДЕ.

МИНЕМ ШИҢГӘН ГӨЛЛӘРЕМ
ТЕРЕЛСЕН ӨЧЕН ТИЗРӘК,
ИРТӘГЕСЕН ҺИЧШИКСЕЗ
«БИШЛЕ» АЛЫРГА КИРӘК.
«БИШЛЕ» АЛЫРГА КИРӘК!

Раушания ВӘЛИЕВА,
БАУЛЫ.

Урысчадан
ФӘНИС ЯРУЛЛИН
тәрҗемәсе.

Рәссам СВЕТЛАНА ФАТТАХОВА

ЦВЕТЫ


НА ОКНЕ МОЕМ ЦВЕТЫ.
УЛЫБАЮТСЯ ОНИ,
БУДТО ЗНАЮТ, ЧТО ПЯТЕРКУ
Я СЕГОДНЯ ПОЛУЧИЛ.

ОБРЯДИЛИСЬ СТЕБЕЛЬКИ
В БЕЛОСНЕЖНЫЕ ЦВЕТКИ,
С ИЗУМРУДОМ МОЖНО СПУТАТЬ
ЭТИ НЕЖНЫЕ ЛИСТКИ!

НА ОКНЕ МОЕМ ЦВЕТЫ.
МОЖЕТ, НЕ ПОВЕРИШЬ ТЫ,
НО КОГДА ПРИНЕС Я ТРОЙКУ,
ВДРУГ ЗАВЯЛИ ВСЕ ОНИ...

ВДРУГ ЗАВЯЛИ ВСЕ ОНИ,
ЧТОБЫ МНЕ СПАСТИ ЦВЕТЫ,
НУЖНО ЗАВТРА ВНОВЬ ИЗ ШКОЛЫ
МНЕ ПЯТЕРКУ ПРИНЕСТИ!

РАУШАНИЯ ВАЛИЕВА,
Бавлы.



Художник СВЕТЛАНА ФАТТАХОВА



Зирәк хөкемдар

(Әфган халык әкияте)

Бер яшүсмергә чит илләргә сәфәр чыгарга кирәк була. Китәр алдыннан, ул күрше картка йөз рупияне сакларга бирә. Бирә дә китеп бара.

Күп илләрне гизеп, егет өенә әйләнеп кайта. Күршесенә кереп, акчасын кайтаруны сорый. Әмма карт явыз һәм комсыз булып чыга. Ул егетнең акчасын беркайчан да күрмәгәнгә салыша. Егет, тәмам боегып, өметен җуеп барганда, мәрхәмәтле кешеләр аңа киңәш бирәләр.

— Хөкемдарга бар да хәйләкәр карттан зарлан,— диләр егеткә.

Егет шулай итә дә. Хөкемдар икесен дә үзенә чакырта. Башта ул картка мөрәҗәгать итә:

— Бу егеттән акча алган идеңме?

Карт, үзенең чал сакалы белән ант итеп, мондый хәлнең булмавын әйтә. Шунда хөкемдар егеттән:

— Ә синең шаһитларың бармы соң? — дип сорый.

Әлбәттә инде, тегенең шаһитлары булмый.

— Яхшы,— ди хөкемдар,— ә син бу картка кайда бирдең акчаңны?

— Бер агач төбендә.

— Ул агачка бар һәм аны минем янга чакыр.

Егет хөкемдар үзеннән көлә торгандыр дип уйлый. Әмма ни эшләсен соң? Ул агач янына китә.

Хөкемдар һәм карт көтә калалар. Ярты сәгать уза. Хөкемдар, көтеп туйган кыяфәт белән:

— Ул үзенең агачына барып җиттеме икән? — дип кычкырып сорый.

— Юк әле,— дип, ялагайланып җавап бирә карт.

Бер сәгать вакыт уза. Хөкемдар яңадан сорый:

— Ә хәзер ул агач янына килдеме?

— Килде,— дип җавап кайтара карт.

Ниһаять, егет әйләнеп килә. Бик кайгырып:

— Агач минем белән килмәде, и зирәк акыллы хөкемдар,— ди.

— Инде моның кирәге дә юк, и намуслы егет,— дип җавап бирә аңа хөкемдар. — Хәзер үзең дә белерсең. Мин күршеңнән, агачка барып җиттеме икән, дип сорадым. Ул, юк әле, дип җавап бирде. Шуннан соң тагын шул ук сорауны кабатладым һәм карт миңа, инде егет кайтып килә, дип җавап кайтарды. Әйт әле, и карт кеше, әгәр ул агач төбендә акча алмасаң, әлеге агачның кайда булуын ничек белә алыр идең?

Карт, гарьләнеп, ачуыннан төкереп куя. Ул үзен алдауларын аңлый. Шуннан соң аңа, кесәсеннән йөз рупия чыгарып, егеткә бурычын кайтарып бирергә туры килә.

Урысчадан
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ
тәрҗемәсе.



Рәссам ИЛДАР ӘХМӘДИ



МУДРЫЙ СУДЬЯ

(Афганская сказка)

Одному юноше надо было поехать в дальние страны. Перед отъездом он отдал на хранение старику соседу сто рупий. Отдал и уехал.

Объездил он много стран и вернулся домой. Пришел к соседу и попросил вернуть деньги. Но старик оказался злым и жадным. Он притворился, что никогда и не видел денег юноши. Юноша совсем было приуныл, но добрые люди научили его.

— Пойди,— сказали они ему,— к судье и пожалуйся на хитрого старика.

Юноша так и сделал. Судья призвал к себе обоих. Сначала он обратился к старику.

— Брал ли ты деньги у этого юноши?

Старик поклялся своей седой бородой, что этого не было. Тогда судья спросил юношу:

— А есть ли у тебя свидетели?

Но, конечно, свидетелей у того не было.

— Хорошо,— сказал судья,— а где ты давал старику эти деньги?

— Под одним деревом.

— Пойди к этому дереву и позови его ко мне.

Юноша подумал, что судья смеется над ним, но что было ему делать? Он пошел к дереву.

Судья и старик остались ждать. Прошло полчаса. Судье как будто надоело ждать. Он воскликнул:

— Дошел ли он до своего дерева?

— Нет еще,— подобострастно ответил старик.

Прошел еще час. Судья опять спросил старика.

— А теперь он пришел к дереву?

— Пришел,— ответил старик.

Наконец юноша возвратился. Печально сказал он судье:

— Дерево не пошло со мной, о мудрый судья.

— Теперь уже этого не нужно, о честный юноша,— ответил ему судья.— Сейчас ты узнаешь почему. Я спросил твоего соседа, дошел ли ты до дерева. Он мне ответил, что еще нет. Потом я спросил его еще, и он мне сказал, что ты уже возвращаешься. Но как, скажи мне, о старец, мог ты знать, где находится это дерево, если ты под ним не брал денег?

Старик злобно плюнул от досады. Он понял, что его перехитрили. Пришлось ему вытащить из кармана сто рупий и отдать свой долг юноше.



Художник ИЛДАР АХМАДИЕВ



Габдулла Тукай

ПЕЧӘН БАЗАРЫ, ЯХУД ЯҢА КИСЕКБАШ

«БАШТАН ҮТКӘННЕ СӨЙЛИМЕН, ТЫҢЛАГЫЗ,
МИН ХАҖИ — БАРДЫМ ХАҖӘ ТУКСАН ТУГЫЗ.

КҮП ТӘВАФ ИТТЕМ ХИҖАЗ СӘХРАСЫНИ,
ҖИДДӘСЕН ҺӘМ МӘККӘСЕН, САНГАСЫНИ.

МИН ГЛАСНЫЙЛЫКТА ТОРМЫШДЫМ ЯНӘ
БУ ШӘҺӘРНЕҢ ДУМАСЫНДА УН СӘНӘ.

ҺӘМ ДӘ МӘСКӘҮДӘН ДӘ МАЛЛАР АЛМЫШЫМ,
СУМЫНА ТУКСАН ТИЕННЕ ЧӘЛМЕШЕМ.

ИТӘ ИРДЕМ КӨН ДӘ БЕР КОРЪӘН ХӘТЕМ,
АЛМЫШЫМ ГОМРЕМДӘ УНБИШЛӘП ХАТЫН.

КИЧ БАРЫР ИРДЕМ «ТӘТӘЙЛӘР РӘТЕ»НӘ,
ӘҮРЕЛЕП КӨНДЕЗ КЕШЕ СУРӘТЕНӘ.


БАР ИДЕ КАРТЛЫКТА АЛГАН ХАТЫНЫМ,
БЕР БАЛАМ — АҺ, КҮЗ НУРЫМ! АҺ, АЛТЫНЫМ!

КАРТ КӨНЕМДӘ БУНЛАР ИПТӘШЛӘР ИДЕ,
ЯХШЫ ЮЛДАШЛАР ВӘ СЕРДӘШЛӘР ИДЕ.

ТАРТЫП АЛДЫ БУНЛАРЫЙ МИННӘН ДИЮ,
СЕЗГӘ ВАҖИБТЫР МИҢА ЯРДӘМ КЫЙЛУ.

АНЛАРЫЙ АЛДЫ ДА КЕРДЕ КОЕГА,
КАЙГЫ КУЙМЫЙ КҮЗЛӘРЕМНЕ УЙКУГА.

(Дәвамы бар.)



Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ



Габдулла Тукай

СЕННОЙ БАЗАР, ИЛИ НОВЫЙ КИСЕКБАШ

СЛЕЗЫ С НОВОЙ СИЛОЙ СТАЛИ ГРАДОМ ТЕЧЬ:
ГОЛОВА СКВОЗЬ ВСХЛИПЫ НАЧИНАЕТ РЕЧЬ:

— Я ХАДЖИ. ВНИМАЙТЕ! МЕККУ ПОСЕЩАЛ,
ТАМ Я ДЕВЯНОСТО ДЕВЯТЬ РАЗ БЫВАЛ.

О СТЕПЯХ ХИДЖАЗА РАССКАЗАТЬ МОГУ,
ПОВИДАЛ ДЖИДДУ Я, ПОВИДАЛ САНГУ.

В ГОРОДЕ КАЗАНИ,— НЕ СОЛГУ, О НЕТ! —
БЫЛ Я ГЛАСНЫМ В ДУМЕ КРЯДУ ДЕСЯТЬ ЛЕТ.

ЗА ТОВАР МОСКОВСКИЙ, КЛАНЯЯСЬ СУДЬБЕ,
ПОЛНЫХ ДЕВЯТЬ ГРИВЕН БРАЛ С РУБЛЯ СЕБЕ.

КАЖДЫЙ ДЕНЬ КОРАН Я ПОЛНОСТЬЮ ЧИТАЛ
И ПЯТНАДЦАТЬ ЖЕНЩИН ЧЕСТНО В ЖЕНЫ ВЗЯЛ.


БУДУЧИ ПРИМЕРОМ ДЛЯ НАРОДА ДНЕМ,
ЗАХОДИЛ В ПОТЕМКАХ Я К КРАСОТКАМ В ДОМ.

ЖИЛ ПОД СТАРОСТЬ МИРНО С МОЛОДОЙ ЖЕНОЙ,
БЫЛ СЫНОК — ОТРАДА, МАЛЬЧИК ЗОЛОТОЙ.

С НИМИ КОРОТАЛ Я СТАРЧЕСКИЕ ДНИ,
ЛУЧШИМИ ДРУЗЬЯМИ БЫЛИ МНЕ ОНИ,

ДИВ УНЕС ПРОКЛЯТЫЙ ОТ МЕНЯ ИХ ПРОЧЬ,
ВЫ ДОЛЖНЫ НЕМЕДЛЯ МНЕ В БЕДЕ ПОМОЧЬ.

(Продолжение следует.)




Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

Әхлакый тәрбия

Каюм Насыйри

Китаб әт-тәрбия



УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ ТӘРБИЯ

Бер падишаһ үзенең углын остазга гыйлем укымага бирде. Остаз күп ижтиһад белән падишаһның углына тәгълим бирде, вә яман нәрсәләрдән тыйды, вә кайчак кыйнады. Бу бала, тәкатьсезлегеннән, атасына кайтып шикаять кыйлды, тәнен ачып күрсәтте. Атасы моңар хафаланып остазны чакыртты, әйтте: «Әй остаз, гавам балаларын бу кадәр җәфа кыйлмайсаң икән, безнең баламызга бу кадәр җәфа вә җәбер күрсәтәсең, ни сәбәпдер?» — диде. Остаз әйтте: «Әй падишаһ, аның өчен ки, гавам балаларына игътибар юкдыр; әмма падишаһ балалары җәфа ни нәрсә, җәбер ни нәрсә икәнен белеп үссеннәр. Таки падишаһ булганнан соң, җәбер вә золым ни икәнен белеп, саклансын. Әгәр падишаһтан вә падишаһ балаларыннан җәбер вә золым башланса, илдән илгә йөртерләр». Вә олуг кешеләрнең вә байларның балаларын, тәрбия вә дә ки тәртип бирүдә гавам балаларыннан артыграк карарга тиеш, ягъни узындырмаенча, тыгызрак тотып тәрбия кыйлырга тиеш, бай, дип, иркенлек кыйлырга ярамый.

Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМ



Нравственное воспитание

Каюм Насыри

Книга о воспитании

НАСТАВЛЕНИЕ ТРИДЦАТЬ ТРЕТЬЕ

Один падишах отдал сына наставнику. Тот с большим усердием принялся за обучение сына падишаха, строго взыскивал с мальчика за все дурное и даже бил иногда. Мальчик не выдержал притеснений учителя и прибежал к отцу с жалобами, показал ему свое тело. Отца огорчило это, и он приказал позвать наставника. «Почему ты так жесток и безжалостен с нашим сыном, о учитель, тогда как с детьми черни обходишься гораздо мягче?» — «О падишах, дурные дела черни не опасны, никто не последует ее примеру, но сын падишаха должен знать, что такое зло. И когда он станет падишахом, пусть остерегается жестокости и несправедливости. Исходя от падишаха или сына падишаха, они становятся особенно опасны. Весть о злых делах владык летит из одной страны в другую и плодит последователей».

Вот почему при обучении и воспитании с потомков людей богатых и знатных следует взыскивать строже, чем с детей простолюдинов, то есть не давать им воли, не позволять лишнего и не баловать вниманием лишь потому, что они из богатых и знатных семей.

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ

ИЗУЧАЕМ ЯЗЫКИ ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

ЮНЫЕ ДРУЗЬЯ!

УРОК 39 ДӘРЕС

«ИЗУЧАЕМ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК»

УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ ДӘРЕС

(Тридцать девятый урок)

1. Балалар өчен чыга торган газета һәм журналлар турында сөйләшәбез.

(Әңгәмәдә укытучы һәм укучылар катнаша).

— *Укучылар, сез балалар өчен татарча нинди газета һәм журналларны беләсез? Яле, Мансур, әйтеп кара.*

— **Мин «Сабантуй», «Җиз кыңгырау» газеталарын беләм.**

— *«Сания, әйт әле, син нинди журналлар беләсең?*

— **«Сабыйга» журналын беләм.**

— *Равил, син нәрсә әйтергә телисең?*

— **Тагын балалар өчен «Зонтик» журналы бар.**

— *Дөрес. Рус телендә дә балалар өчен журналлар чыга. Мәсәлән, «Мурзилка», «Веселые картинки», «Колобок» һ. б.*

(Укытучы укучыларга журналларны күрсәтә).



Укытучы: — Менә сез II һәм III сыйныф укучылары. Айгөл, син нинди газетаны яки журналны укыйсың?

Айгөл: — Мин «Җиз кыңгырау» газетасын алам һәм аны укып барам.

— *Ә син, Сәлимә?*

Сәлимә: — Мин «Сабыйга» журналын укырга яратам. Миңа хайваннар һәм кошлар турындагы мәкаләләр ошый.

— *Әлфия, син нәрсәләр укыйсың?*

Әлфия: — Мин дә «Сабыйга» журналын укыйм. Андагы кызыклы хәбәрләр белән танышам.

— *Таһир, сине нинди хәбәрләр кызыксындыра?*

Таһир: — Миңа тарих турында язганнар ошый.

— *Мансур, сиңа барысы да аңлашыламы?*

Мансур: — Аңлашылмаса, әти-әнидән, апамнан сорыйм.
— *Яхшы, укучылар. Сез шулай газета-журналларны даими укып барыгыз.*



<u>СҮЗЛЕК:</u>

сыйныф — класс
мәкалә — статья
хәбәрләр — заметки
тарих — история
барысы да — все
тагын — еще
сорыйм — спрашиваю
аңлашыламы? — понятно ли?
белергә — знать
әйт әле — скажи-ка
өстәргә — добавлять
укырга яратам — люблю читать
ошый — нравится
танышам – ознакомлюсь
кызыксындыра — интересует

2. Шигырьне укып чыгыгыз, эчтәлеген сөйләп бирегез һәм күңелдән ятлагыз.

Бакчада.

Сирень, юкә агачлары
Тәмле ис тараталар.
Чәчәкләргә бал кортлары
Кунарга яраталар.

Бал кортлары бик җитезләр,
Тырышып эшли алар.
Иртәдән кичкә кадәрле
Юкәдән бал җыялар.

(Галимҗан Латыйп.)



3. Хәтердә тот:

Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне килеш формалары һәм бәйлекләр ярдәмендә ачыклап килүче җөмлә кисәге тәмамлык дип йөртелә:
<u>дәфтәргә</u> яздым, <u>китапны</u> алдым, <u>Саниядән</u> сорадым, <u>Маратка</u> әйттем.

Җөмләләрдә шундый тезмәләрне күрсәтегез, аңлатып бирегез.

Җыр <u>өйрәтте</u> <u>мине</u> хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.

(Муса Җәлил.)

Рәссам Зөфәр Хәким ☐ Художник Зуфар Хакимов


Этисе Маратка кызыклы китап алды.
Фәния мәктәпкә Элфия белән барды.

4. Җөмлә төзү һәм аны тулыландыру күнегүләре:



Мин бардым.

Мин урманга бардым.
Мин бүген урманга бардым.
Мин бүген Наил белән урманга бардым.



Җавап бирегез:
Һәр җөмләдә нинди сүз өстәлеп бара? Шул тәртиптә үзегез җөмләләр төзегез.

5. Бер-берсенә мәгънә ягыннан якын булган сүзләрне аерып алыгыз. Матур, чибәр сүзләре кергән җөмләләр төзегез.

Шатлык, чибәр, җитез, куаныч, өлгер, олылау, йөз, матур, зурлау, йөгерү, бит, сылу, чабу.

6. Кара-каршы сөйләшегез — берегез кояш булсын.

Әйтче, кояш!

— Әйтче, кояш, синең нурлар
Һәммәсе ничәү икән?
— Нурларымның һәммәсен дә
Мин сезгә бүләк итәм!

— Әйтче, кояш, нурларыңда
Җылына ничә кешең?
— Санарга минем вакыт юк,
Иркәләү — минем эшем!

(«Дуслашасым килә» китабыннан.)



Урыс теленә тәрҗемә итегез.

7. Табышмакларны укып чыгыгыз.

Алар нәрсәне белдерә?

Кечкенә генә кунача,
Утыз ике кодача
Утыралар кунакта.

(Тешләр)

Берәү сөйли, икәү тыңлый,
Икәве карап тора.

(Тел, колак, күз)

Дәресне филология фәннәре докторы, профессор, академик ***ВАХИТ ХАКОВ*** *алып бара.*



Урок ведет доктор филологических наук, профессор, академик ***ВАХИТ ХАКОВ.***

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ Художник ЗУФАР ХАКИМОВ



Язарга өйрәнәбез!



Үткәннәрне кабатлыйбыз.

алма ата ана абага

каен усак имән

тәрәзә мәктәп

әйтергә хәзерләргә

тормыш очрашу

ай гөл бөтен

озын мөгез

Рөстәм Хәсән Гөлсем

Бакчада алмагач үсә

Әдип укый.


Сәлимә яза.

Хәлим урамга чыга.

Ул дустын озата.



Учимся писать!



АТ

Тарту көче буларак атларның саны кискен кимү 1950 елдан башлана, әле бу вакытта алар 2 миллион 400 мең баш исәпләнә. Әмма безнең көннәрдә дә ат элеккечә хуҗалыкта файдаланыла, чөнки аның трактордан өстенлекләре бар: ул арзанрак тора, гомер озынлыгы ягыннан караганда да отышлырак. Ләкин шунысы да бар: эш бетүгә, атны ашатырга, карарга кирәк һәм шуңа күрә хуҗасы озаккарак китә алмый. Трактор исә, хуҗасын көтеп, күп көннәр тора ала..



Атның киң таралган токымнарына бретон, контуаз, арденн һәм першерон керә, башка токымнары азрак санда. Атларның першерон һәм бретон токымнарының авырлыгы, ким дигәндә, 600 кг, шул ук вакытта, атланып йөри торган токымнарының авырлыгы уртача 400—450 кг.

Атларны кулга өйрәтүгә беренче омтылышлар моннан алты мең ел элек Якын Көнчыгышта ясалган булса кирәк. Аны баштарак атланып йөрү өчен файдаланалар, ә аннары җигү өчен дә кулланыла башлый.

Бүген соңгы кыргый атлар Кытай һәм Монголия чикләрендәге далаларда тереклек итәләр. Алар, бу токымны XIX гасырда ачкан һәм сурәтләгән урыс тикшеренүчесе исеме белән, «Пржевальский атлары» дип йөртелә. Кыргый атларның тарпаннар дип аталган башка токымнары XIX гасырда юкка чыккан.

Урысчадан
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ
тәрҗемәсе.



Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ



ЛОШАДЬ

Резкое снижение количества лошадей, используемых в качестве тягловой силы, началось с 1950 г., когда их поголовье еще насчитывало 2 миллиона 400 тысяч. Но и в наши дни лошадь по-прежнему используется в хозяйстве, ибо имеет ряд преимуществ перед трактором: она и стоит дешевле, и продолжительность ее жизни также является козырем. Но зато, когда работа закончена, лошадь нужно кормить, ухаживать за ней, и хозяин не имеет возможности отлучиться надолго, в то время как трактор может поджидать своего хозяина в течение многих дней...

Наиболее распространенными породами являются бретонская, контуазская, арденнская и першеронская; другие породы представлены гораздо меньшим количеством животных. Лошади першеронской и бретонской породы весят, по крайней мере, 600 кг, в то время как лошадь для верховой езды весит в среднем 400—450 кг.

Первые попытки приручить лошадь имели место, по всей видимости, шесть тысяч лет тому назад на Ближнем Востоке, где сначала ее использовали для верховой езды, а затем и как тягловую силу.

Сегодня последние дикие лошади живут в степях на границах Китая и Монголии; их называют «лошадь Пржевальского» — по имени русского исследователя, который открыл и описал эту породу в XIX в. Другие породы диких лошадей, назывались тарпанами, исчезли в XIX веке.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ



БАЛАЛАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

АКУЛАЛАР КАЙДА ЯШИЛӘР?

Акулаларның 150дән артык төре билгеле. Аларның барысы да, бер төрдән кала, диңгез суында яшиләр. Үзәк Америкада Никарагуа күле бар, анда төче суда яши торган акула тереклек итә.

Акулалар ниндидер бер җирдә генә яшәмиләр, ә бәлки табыш эзләп йөзләрчә миль йөзәләр. Зур акулаларның күпчелеген нигездә ачык диңгезләрдәге су өстендә очратырга мөмкин. Ләкин аларның тирән океан төбендә яши торганнары да бар. Бәләкәйрәк акулалар гадәттә яр буйларында яшиләр һәм аларны җылы һәм уртача климат булган күпчелек диңгезләрдә очратып була.

Күпләр акулаларны бик куркыныч дип саныйлар. Ә чынбарлыкта исә хәтәр акулалар һәм зыянсыз акулалар бар. Мәсәлән, еш кына корабльләр артыннан йөзеп баручы акулалар — алар зыянсыз «чүп савытлары», корабльләр калдырган ризык калдыкларын җыеп баручылар гына. Ул акулалардан хәтта бәләкәй балыклар да курыкмыйлар.


Шулай ук кайбер бик зур акулалар да, әгәр аларга башлап һөҗүм итмәсәң, куркыныч түгелләр. Шундый акулаларның берсе — кит акуласы. Аны Урта диңгездә, Тын океанда һәм Флоридадан ерак булмаган урыннарда Кариб диңгезендә очратырга мөмкин. Аның озынлыгы еш кына 11 метрдан артып китә, ә авырлыгы исә 13 тонна.

Дәү акула — янә бер «куркынычсыз» зур акулаларның берсе. Ул Төньяк Атлантикада иң эре балык, аның озынлыгы 13 метрдан артыграк була. Ул судан аркасын чыгарып кояшта иркәләнергә ярата.

Ләкин барлык балыклар арасында иң дәһшәтлесе — озынлыгы кайчакта 12 метрга кадәр җитә торган дәү ак акула. Ул инде кешеләргә ике дә уйлап тормыйча һөҗүм итә.

Урысчадан
ЛИЛИЯ СӘХАПОВА
тәрҗемәсе.

Рәссам АЛЛА АЙСИНА







ДЕТСКАЯ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ

ГДЕ ЖИВУТ АКУЛЫ?

Существует более 150 разновидностей акул. Все они, кроме одного вида, живут в морской воде. В Центральной Америке есть озеро Никарагуа, где живет пресноводная акула.

Акулы не обитают в каком-то одном месте, а проплывают сотни миль в поисках добычи. Большинство больших акул в основном можно встретить в открытом море у поверхности воды. Но есть и такие, которые водятся глубоко у океанского дна. Акулы поменьше обычно живут возле побережий, и их можно встретить в большинстве морей там, где теплый и умеренный климат.

Многие считают акул очень опасными. На самом деле есть акулы опасные, а есть — безвредные. Например, акулы, которые часто следуют за кораблями,— это безвредные «мусорщики», которые подбирают остатки пищи с кораблей. Этих акул не боятся даже маленькие рыбки.

Точно так же не опасны и некоторые очень большие акулы, если на них не нападать. Одна из таких акул — китовая акула. Ее можно встретить в Средиземном море, в Тихом океане и Карибском море неподалеку от Флориды. Длина ее иногда превышает 11 метров, а вес — 13 тонн.

Гигантская акула — еще одна из «безопасных» больших акул. Это самая крупная рыба Северной Атлантики, длина ее бывает более 13 метров. Она любит понежиться на солнышке, высунув спину из воды.

Но самая ужасная из всех рыб — гигантская белая акула, достигающая иногда в длину 12 метров. Она-то уж точно нападает на людей.

Художник АЛЛА АЙСИНА

ЧЫН ДУС

(Әкият)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер аю. Урманда иң көчле җанвар булса да, аның дуслары юк икән. Моңа аю бик кайгырган. Ул сорап та караган, әмма бер киек-җәнлек тә ризалашмаган. Чөнки барысы да аюдан курыкканнар.

Шулай күңелсезләнеп йөргәндә, аның янына тиен килгән һәм: «Аю абзый, әгәр теләсәң, мин синең дустың булырмын»,— дигән.

Аю тиенне бер дә рәнҗетмәгән, аңа һәрвакыт ярдәм итә, гөмбәле, чикләвекле урыннарны күрсәтә икән. Тиен дә бик акыллы, уңган, ярдәмчел дус булып чыккан. Җәнлекләр арасындагы бәхәсләрне хәл иткәндә, ул аюга төпле киңәшләр биргән. Шулай аларның дуслыклары ныгыган.

Аюның дәрәҗәсе көннән-көн үскән. Инде аның белән дуслашырга теләүчеләр дә күп икән. Әмма аю берсенең дә дуслыгын кабул итмәгән: «Чын дус берәү генә була ул»,— дигән.

Ә сез ничек уйлыйсыз, дуслар?!

АЙФИРАЗ ЗАРИФУЛЛИН.
10 яшь.